Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Пестречинского
муниципального района
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль
районы
башкарма комитеты
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«12» сентябрь, 2022 ел

№ 625

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында 2022-2023 елларда җылыту сезоны башлану турында

Районның ягулык-энергетика комплексы предприятиеләрендә 2022-2023 еллар җылылык сезонын вакытында һәм сыйфатлы башлау максатыннан һәм тышкы һава температурасы кимү сәбәпле, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның 13 сентябреннән районның барлык җылыту һәм котельныйларында 2022-2023 җылыту сезонын башлау.

2. Район предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләренә ягулык-энергетика ресурслары белән тәэмин итүчеләр белән килешүләр төзүне тәмамларга, бөтен җылыту сезоны дәвамында чыгымнарны вакытында финанслауны тәэмин итәргә.

2.1. Учреждение җитәкчеләре һәм идарәче компанияләр заявкалары буенча мәгариф, сәламәтлек саклау, балалар учреждениеләре, торак йортларны беренчел җылылык белән тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе

А. В. Хәбибуллин